# КАРАР

04 декабрь, 2019 ел №1

Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 4 декбрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 800 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Вахит авылы Татарстан, Тукай урамнарына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Вахит авылы Беренче май, Яшьләр, Чишмә урамнары буенча бетон белән чокырлар ямау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Вахит авылында юлларны кардан чистарту;
- Вахит авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау;
- Вахит авылының Клуб урамына юл билгеләре, ясалма тигезсезлекләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Вахит авылында чишмәне ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Вахит авылында Яңа Чишмә төзү;проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- территорияне яшелләндерү, газоннарны төзекләндерү, Вахит авылында агач, үсентеләр сатып алу, утырту;
- Янил авыл җирлеге өчен газонокосилка, бензин триммерлары сатып алу;
- брусчатка сатып алу һәм җәю;
- Вахитов авылы паркын карап тоту;
- Вахитов авылында җәяүлеләр күпере төзү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 643 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 343 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 343 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 800 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Вахит авылы Татарстан, Тукай урамнарына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Вахит авылы Беренче май, Яшьләр, Чишмә урамнары буенча бетон белән чокырлар ямау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Вахит авылында юлларны кардан чистарту;

- Вахит авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау;

- Вахит авылының Клуб урамына юл билгеләре, ясалма тигезсезлекләр сатып алу һәм урнаштыру;

- Вахит авылында чишмәне ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Вахит авылында яңа Чишмә төзү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- территорияне яшелләндерү, газоннарны төзекләндерү, Вахит авылында агач, үсентеләр сатып алу, утырту;

- Янил авыл җирлеге өчен газонокосилка, бензин триммерлары сатып алу;

- брусчатка сатып алу һәм җәю;

- Вахитов авылы паркын карап тоту;

- Вахитов авылында җәяүлеләр күпере төзү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Янил авыл җирлеге башлыгы И.Х.Корбанов